СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**
**29.12.2025**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 51**

Җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 15 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы « Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. 2026 елдан җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен кабул итәргә.

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр, авыл җирлекләренең Башкарма комитетлары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында 1 нче кушымта нигезендә, әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә килешүләр төзергә.

3. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру Зеленодольск муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләр бюджетларыннан Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган финанс чаралары исәбеннән гамәлгә ашырыла (хисаплау методикасы 3 нче кушымта нигезендә бирелгән), шулай ук «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән каралган очракларда һәм тәртиптә үз матди ресурсларыннан һәм финанс акчаларыннан өстәмә файдаланырга хокуклы.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советының социаль-икътисадый үсеш, бюджет – финанс мәсьәләләре, муниципаль милек һәм эшкуарлыкны үстерү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Советы рәисе** **М.П. Афанасьев**

Зеленодольск муниципаль районы
Советының 2025 елның
29 декабрендәге 51 номерлы
карарына
1 нче кушымта

**Зеленодольск муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре исемлеге**

1. Васильево шәһәр тибындагы поселогы
2. Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы
3. Әйшә авыл җирлеге
4. Акъегет авыл җирлеге
5. Бишнә авыл җирлеге
6. Олы Ачасыр авыл җирлеге
7. Большие Ключи авыл җирлеге
8. Олы Карагуҗа авыл җирлеге
9. Олы Шырдан авыл җирлеге
10. Олы Җәке авыл җирлеге
11. Күгәй авыл җирлеге
12. Күгеш авыл җирлеге
13. Мамадыш-Әкил авыл җирлеге
14. Мулла Иле авыл җирлеге
15. Түбән Урысбага авыл җирлеге
16. Новопольский авыл җирлеге
17. Норлат авыл җирлеге
18. Октябрь авыл җирлеге
19. Осиново авыл җирлеге
20. Раифа авыл җирлеге
21. Рус Әҗиле авыл җирлеге
22. Свияжск(Зөя)авыл җирлеге
23. Өтәшкә авыл җирлеге

Зеленодольск муниципаль районы
Советының 2025 елның
29 декабрендәге 51 номерлы
карарына
2 нче кушымта

**_________жирлек Башкарма комитеты һәм Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты арасында җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында**
**КИЛЕШҮ №**

Зеленодольск шәһәре _______________

Устав нигезендә эш итүче зат буларак бер яктан Зеленодольск муниципаль районы _______________________ җирлеге Башкарма комитеты, алга таба «Җирлек башкарма комитеты» дип аталучы, һәм Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты исеменнән, алга таба «Район башкарма комитеты» дип аталучы, Устав нигезендә эш итүче Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе ____________________________, икенче яктан, бергә «Яклар» дип аталучы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Зеленодольск муниципаль районының «________________________________________җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы һәм Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

1. КИЛЕШҮ ПРЕДМЕТЫ

Әлеге Килешү предметы булып Җирлек башкарма комитетының Район башкарма комитетына муниципаль хезмәт күрсәтү - җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру тора.

2. ЯКЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

2.1 Җирлек башкарма комитеты түбәндәгеләргә бурычлы:

- 1 нче бүлектә күрсәтелгән вәкаләтләрне (алга таба- тапшырылган вәкаләтләр) гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган бюджетара трансфертлар рәвешендә финанс средстволарны тапшырырга;
- тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны бирергә;
- Район башкарма комитеты тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда консультатив һәм методик ярдәм күрсәтергә.

2.2 Җирле башкарма комитет түбәндәге хокукка ия:

- Район башкарма комитеты тапшырылган вәкаләтләрне үтәүне, шулай ук әлеге килешүнең 3 нче бүлегендә күрсәтелгән финанс чараларын максатчан куллануны контрольдә тотырга. Бозулар ачыкланган очракта, Район башкарма комитеты тарафыннан үтәлүе мәҗбүри булган язма таләпләрне хәбәр ителгән вакыттан алып билгеле бер срокта җибәрергә;
- тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру белән бәйле булган, шулай ук

бу максатларга бирелгән финанс чараларыннан файдалану буенча Район башкарма комитетыннан кирәкле мәгълүмат, материаллар һәм документлар соратып алырга;

- тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча Район башкарма комитетына тәкъдимнәр кертергә;

- килешү имзаланганнан соң утыз көн эчендә, түләүсез файдалану килешүе буенча тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен, кирәкле матди ресурсларны районның җирле үзидарә органнарына тапшырырга.

2.3 Район башкарма комитеты түбәндәгеләргә бурычлы:

- закон таләпләренә туры китереп тапшырылган вәкаләтләрне тиешенчә үтәүне, шул исәптән Җирлек башкарма комитеты тарафыннан тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга гына бирелгән финанс средстволарыннан максатчан файдалануны гамәлгә ашырырга (тәэмин итәргә) ;

- тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча Район башкарма комитеты тарафыннан ачыкланган бозуларны бетерү турында Җирлек башкарма комитеты тәкъдим иткән язма таләпләрне бер айдан да соңга калмыйча (әгәр таләптә башка вакыт күрсәтелмәгән булса) бозуларны бетерү буенча чаралар күрергә һәм бу хакта кичекмәстән Җирлек башкарма комитетына хәбәр итәргә;

- килешү гамәлдән туктаган очракта файдаланылмаган финанс чараларын кире кайтарырга;

- тапшырылган вәкаләтләрне тиешенчә үтәү мөмкин булмаган очракта, вәкаләтләрне үтәү мөмкинлеге булмау турында билгеле булган вакыттан алып ун көн эчендә Җирлек башкарма комитетына язма рәвештә хәбәр итәргә.

2.4 Район башкарма комитеты түбәндәге хокукка ия:

- вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Җирлек башкарма комитеты тарафыннан тапшырыла торган финанс чараларын алырга һәм файдаланырга;

- тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны Җирлек башкарма комитетыннан соратып алырга;

- тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә матди ресурслардан һәм башка финанс чараларыннан законнар нигезендә файдаланырга;

- тапшырылган вәкаләтләрне башкаруга юнәлдерелгән, гамәлдәге законнарга каршы килмәгән, теләсә нинди башка эшләрне гамәлгә ашырырга.

- шушы Килешүнең 1 бүлегендә каралган вәкаләтләрне Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Күрсәтмәсе нигезендә «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарәсенең башкарма-боерык биру органнарына тапшырырга.

## 3. БЮДЖЕТАРА ТРАНСФЕРТЛАРНЫҢ ЕЛЛЫК КҮЛӘМЕН БИЛГЕЛӘҮ ТӘРТИБЕ ҺӘМ КҮЧЕРҮ СРОКЛАРЫ

3.1. Әлеге Килешү предметы буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру ел саен Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан бюджет законнары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбенә гамәлгә ашырыла.

3.2. Яклар ел саен, әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган кушымта нигезендә, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләмен билгели.

3.3. Район башкарма комитеты бюджетара трансфертларны максатчан файдаланмаган очракта, алар Җирлек башкарма комитеты таләбе буенча ун көн эчендә җирлек бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

3.4. Бюджетара трансфертлар Җирлек башкарма комитеты тарафыннан ай

саен Район башкарма комитетына , агымдагы елның 10 числосына кадәр, бюджетара трансфертларның 1/12 күләмендә күчерелә

3.5. Бюджетара трансферт күләме, аны исәпләгәндә кулланыла торган күрсәткечләр үзгәргәндә, яклар килешүе буенча үзгәртелергә тиеш.

## 4. ТАПШЫРЫЛГАН ВӘКАЛӘТЛӘРНЕ КУЛЛАНУНЫ КОНТРОЛЬДӘ ТОТУ

4.1. Җирлек башкарма комитеты тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, Җирлек башкарма комитетының дәлилләнгән соравы буенча тапшырылган финанс чараларыннан һәм матди ресурслардан файдалану турында Район башкарма комитетыннан кирәкле мәгълүмат соратып ала.

4.2. Район башкарма комитеты Җирлек башкарма комитетына ел саен агымдагы елның 31 декабренә кадәр вәкаләтләрне үтәү, тапшырылган финанс чараларын һәм матди ресурсларны куллану турында хисап, шулай ук әлеге Килешү предметына кагылышлы аерым сораулар буенча башка мәгълүмат җибәрә.

4.3. Бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын контрольдә тотуны гамәлдәге законнары нигезендә Җирлекнең башкарма комитеты, муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыручы орган башкара.

## 5. КИЛЕШҮНЕҢ ГАМӘЛДӘ БУЛУ СРОГЫ

5.1. Әлеге Килешү бастырылган көннән үз көченә керә һәм 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

5.2. Әгәр дә әлеге Килешүнең гамәлдә булу вакыты тәмамланугa бер ай кала бер генә Як та Килешүне өзү ниятен икенче Якка хәбәр итмәсә, ул 5 елга озайтылган дип санала.

## 6. КИЛЕШҮНЕҢ ГАМӘЛДӘ БУЛУЫН ТУКТАТУ НИГЕЗЛӘРЕ ҺӘМ ТӘРТИБЕ

6.1. Килешү, Якларның Килешүендә башкасы каралган очраклардан тыш, срок үткәннән соң гамәлдә булуын туктата.

6.2. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда түбәндәге очракларда туктатылырга мөмкин:

- Яклар килешүе буенча.
- бер яклы тәртиптә түбәндәге очракта:
- Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарын һәм (яисә) Татарстан Республикасы законнарын үзгәртү, нәтиҗәдә Район башкарма комитеты тарафыннан вәкаләтләрне үтәү мөмкин булмый башласа, йә килеп туган шартларда әлеге вәкаләтләр Җирлек башкарма комитеты тарафыннан мөстәкыйль рәвештә нәтиҗәлерәк гамәлгә ашырылырга мөмкин булса;
- әлеге Килешү нигезендә Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәсә яисә тиешенчә үтәмәсә.

6.3. Әлеге килешүне өзү турында хәбәрнамә язма рәвештә җибәрелә. Килешү күрсәтелгән хәбәрнамә җибәрелгән көннән соң 30 көн узгач өзелгән дип санала.

6.4. Әлеге Килешү вакытыннан алда туктатылган очракта, Район башкарма комитеты Җирлек башкарма комитетына вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган файдаланылмаган финанс чараларын кире кайтара.

## 7. ЯКЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

7.1. Яклар Россия Федерациясе законнары һәм әлеге Килешү нигезендә, әлеге Килешүдә каралган бурычларны үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен җавап

тоталар

7.2. Әлеге Килешү буенча бурычларны үтәмәү яки тиешенчә үтәмәү законнарда каралган җаваплылык башлануга нигез булырга мөмкин.

## 8. КИЛЕШҮНЕ ҮТӘМӘГӘН ӨЧЕН ФИНАНС САНКЦИЯЛӘРЕ

8.1. Әлеге Килешү буенча Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән өчен, гаепле Як икенче Якка, әлеге килешүгә кушымтада каралган финанс средстволары күләменең 0,1 процент размерында штраф түли.

8.2. Штраф түләү Якларның бурычларын әлеге Килешү буенча алга таба үтәүдән азат итми.

## 9. БӘХӘСЛӘРНЕ ЧИШҮ ТӘРТИБЕ

9.1. Әлеге Килешүне гамәлгә ашыру белән бәйле бәхәсләр, Якларның сөйләшүләр алып бару һәм башка килештерү процедураларын куллану юлы белән хәл ителә.

9.2. Бәхәсне сөйләшүләр уздыру һәм башка килештерү процедураларыннан файдалану юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнар нигезендә суд тәртибендә каралырга тиеш.

## 10. ЙОМГАКЛАУ НИГЕЗЛӘМӘЛӘРЕ

10.1. Әлеге Килешүгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Якларның үзара ризалыгы белән кертелә һәм язма рәвештә өстәмә килешү белән рәсмиләштерелә. Өстәмә килешүләр әлеге килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

10.2. Әлеге Килешүдә җайга салынмаган мәсьәләләр буенча Яклар гамәлдәге законнарга таяна.

10.3. Чираттагы финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар РФ БК 242 статьясына ярашлы рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлеге (шәһәр, авыл җирлеге) бюджетына кайтарылырга тиеш.

10.4. Әлеге Килешү бертигез юридик көчкә ия булган 2 (ике) нөсхәдә, һәр Як өчен берәр нөсхәдә төзелде.

10.5. Әлеге килешүгә «Бюджетара трансфертлар күләме» кушымтасы кушылып бирелә.

## 11. ЯКЛАРНЫҢ ИМЗАЛАРЫ

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы ________________җирлек башкарма комитеты җитәкчесе | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| ________________/_________________ | ________________/_________________ |
| «___» ___________________20__ел. | «___» ___________________20__ел. |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән ____________авыл җирлеге башкарма комитеты арасында җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында Килешүгә

1 нче кушымта

Җир эшләрен башкаруга рөхсәт бирү буенча вәкаләтләрнең тапшырыла торган өлешен гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләме**.**

Әлеге Килешү предметы буенча вәкаләтләрнең бер өлеше ел саен Зеленодольск муниципаль районы ________________җирлек бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән гамәлгә ашырыла. Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләме ____________ сум тәшкил итә.

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы ________________җирлек башкарма комитеты җитәкчесе

_______________/_________________

«___» __________________ 20__ ел.

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе

_______________/________________

«___» ___________________20__ ел.

Зеленодольск муниципаль районы
Советының 2025 елның 29
декабрендәге 51 номерлы
карарына
3 нче кушымта

**2026 елда**
**җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен Зеленодольск муниципаль районының авыл җирлекләре бюджетыннан муниципаль район бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертларны исәпләү методикасы.**

1. Зеленодольск муниципаль районының авыл җирлекләре бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бюджетара трансфертлар (алга таба - бюджетара трансфертлар) җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга бәйле, шул исәптән: хезмәт өчен түләүгә, мөлкәтне карап тоту буенча хезмәт күрсәтүләргә, төп средстволарның һәм матди запасларның бәясен арттыру чыгымнарын каплауга.

2. Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү вәкаләтләренең бер өлешен башкару өчен бюджетара трансфертлары күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

**Sмбт. = Соу х Чску,**

биредә:
Sмбт – җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга бюджетара трансфертлар күләме;
Ссоу – җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга бер хезмәт күрсәтү бәясе(1 нче кушымта);

Чску – хисаплы 3 ел өчен хезмәт күрсәтүләрнең уртача саны (2 нче кушымта).

Бюджетара трансфертларны исәпләгәндә сумма бөтен санга кадәр түгәрәкләнә.

3. Бюджетара трансфертлар катгый максатчан билгеләнештә була һәм Җирлек башкарма комитеты тарафыннан җир кишәрлекләре җитештерүгә ордер (рөхсәт) бирү вәкаләтләренең бер өлешен Район башкарма комитетына тапшыру турындагы Килешүләрдә күрсәтелгән максатларга тотыла.

1 нче кушымта

| | Штат расписаниесе буенча елга өстәмәләр белән хезмәт өчен түләү | ЕСН, 30,2%, сум. | 1 сәгать эш бәясе, сум. (гр.2+гр.3)/1953 сәг.) | Бер хезмәтне рәсмиләштерү өчен вакыт, сәгать | Бер хезмәткүрсәтүнең бәясе, сум. гр.5*гр.6. |
|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | фонды, сум. | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 5 | 6 | 7 |
| ПТОның баш белгече | 465 372 | 140 543 | 310 | 13 | 4030 |

2 нче кушымта

| № т/б | Авыл җирлеге | Барлыгы 2022 елдан 2024 елга кадәр хезмәтләр күрсәтелде. | Уртача күрсәткече | Елга Sмбт, сум | Айга Sмбт, сум |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | Васильево шәһәр тибындагы поселогы | 112 | 37 | 149 110 | 12 426 |
| 2 | Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы | 8 | 3 | 12 090 | 1 008 |
| 3 | Әйшә авыл җирлеге | 46 | 15 | 60 450 | 5 038 |
| 4 | Акъегет авыл җирлеге | 0 | 0 | 12 | 1 |
| 5 | Бишнә авыл җирлеге | 2 | 1 | 4 030 | 336 |
| 6 | Олы Ачасыр авыл җирлеге | 4 | 1 | 4 030 | 336 |
| 7 | Большие Ключи авыл җирлеге | 26 | 9 | 36 270 | 3 023 |
| 8 | Олы Карагуҗа авыл җирлеге | 23 | 8 | 32 240 | 2 687 |
| 9 | Олы Шырдан авыл җирлеге | 0 | 0 | 12 | 1 |
| 10 | Олы Җәке авыл җирлеге | 2 | 1 | 4 030 | 336 |
| 11 | Күгәй авыл җирлеге | 1 | 0 | 12 | 1 |
| 12 | Күгеш авыл җирлеге | 1 | 0 | 12 | 1 |
| 13 | Мамадыш-Әкил авыл җирлеге | 0 | 0 | 12 | 1 |
| 14 | Мулла Иле авыл җирлеге | 0 | 0 | 12 | 1 |
| 15 | Түбән Урысбага авыл җирлеге | 0 | 0 | 12 | 1 |
| 16 | Новопольский авыл җирлеге | 2 | 1 | 4 030 | 336 |
| 17 | Норлат авыл җирлеге | 3 | 1 | 4 030 | 336 |
| 18 | Октябрь авыл җирлеге | 9 | 3 | 12 090 | 1 008 |
| 19 | Осиново авыл җирлеге | 96 | 32 | 128 960 | 10 747 |
| 20 | Раифа авыл җирлеге | 1 | 0 | 12 | 1 |
| 21 | Рус Әҗиле авыл җирлеге | 0 | 0 | 12 | 1 |
| 22 | Свияжск(Зөя)авыл җирлеге | 4 | 1 | 4 030 | 336 |
| 23 | Өтәшкә авыл җирлеге | 0 | 0 | 12 | 1 |
| | Барлыгы | | 113 | 455 50 | 37 959 |